| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 март № 138

г. Казань

2016 елда агросәнәгать комплексына
дәүләт ярдәме чаралары турында

«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган 2016 елга финанслау күләмнәрен агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен бүлү;

2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнмәгән ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда орлык бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә бәйләнмәгән ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда үзенчәлекле һәм элита орлык сатып алу өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда күпъеллык җимешле һәм җиләкле куаклар утырту һәм аларны тәрбияләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда кулланылыштан чыккан иске бакчаларны төпләү һәм төпләнгән мәйданнарны сөрү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда әче җирләрне известь белән ашлау буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда мелиорация эшләре буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда мелиорация эшләрен үткәрү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда үзендә эшкәртү өчен сатылган һәм (яки) төяп озатылган 1 килограмм сөткә чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга җәнлек үрчетү хуҗалыкларына субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын үрчетү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда итчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә булышлык күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда авыл хуҗалыгы иминиятләве шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентлар түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда кече формадагы хуҗалык алып баручылар алган озак вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процентлар түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процентлар түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик яңарту өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда мелиорация объектларын техник яктан яңадан кораллландыру өчен субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда ит, йон һәм күн чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату буенча авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативлары, әзерләү оешмалары һәм кулланучылар кооперацияләре предприятиеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда матди-техник базаларын үстерү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына ярдәм күрсәтүгә грантлар бирү тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең аграр профильдәге махсус белемле белгечләр әзерләү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы белгечләренә дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлар бирү тәртибе;

2016 елда агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләр һәм эшләргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлар бирү тәртибе;

2016 елда ветеринария-санитария сәламәтләндерүе буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасы территориясендә дуңгызларның африка

чумасын алып керүне һәм таратуны булдырмау буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасында эрозиягә каршы һәм кыр саклый торган урман утырмаларын булдыру буенча чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр арасыннан крестьян (фермер) хуҗалыклары, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, файдалана торган җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда эшли башлаучы фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлар һәм (яки) бер тапкыр ярдәм бирү тәртибе;

2016 елда гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзелеше буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга башмак таналар һәм тана сыерларның товарлы һәм нәселле баш исәбен сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга ана кәҗәләрнең нәселле баш исәбен сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга яшь кошлар (күркә, каз, үрдәк, бройлер чебиләр) сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга сыерларны ясалма аталандыру буенча хезмәтләргә чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга өч яшьтән зур булган бияләрне карап тоту өчен азык алуга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнарга сыерларга кирәк-ярак җиткерү буенча ветеринария профилактикасы чараларын үткәрүгә чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда җимеш саклау объектларын төзү һәм (яки) яңарту өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда бәрәңге саклау һәм яшелчә саклау объектларын төзү һәм (яки) яңарту өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда теплица комплекслары объектларын төзү һәм (яки) яңарту өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) яңарту өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның

бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

«2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ит терлеген үрчетү» ведомство максатчан икътисадый әһәмияттәге төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2016 елда субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлеге базарларын җайга салу өлкәсендә аерым чараларны финанслау тәртибе;

2016 елда оешмалар мөлкәтенә салым түләү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалыгын алып баручы гражданнардан тыш), оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына субсидияләр бирү тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен каралган ассигнованияләр исәбеннән 2016 елда конкурс нигезендә бирелә торган грантларның гамәлгә куючысы булырга:

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы белгечләренә – 10,0 млн. сум күләмендә;

агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструктор һәм технологик эшләр алып бара торган милекнең барлык төрендәге оешмаларга – 20,0 млн. сум күләмендә;

авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына, матди-техник базаларын үстерү өчен – 10,0 млн. сум күләмендә;

эшли башлаучы фермерларга – 40,0 млн. сум күләмендә;

крестьян (фермер) хуҗалыкларына – 55,0 млн. сум күләмендә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин